**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МОНАСТЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392, Республика Татарстан,
Тетюшский район, с. Монастырское, ул. Комсомольская, д. 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422392, Татарстан Республикасы,
Тәтеш районы, Монастырск авылы,
Комсомол урамы, 33

Тел. (84373)5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru
ОКПО 92655464, ОГРН 1021606556883, ИНН/КПП:1638001649/163801001

# КАРАР

**27 апрель 2020 ел** **№ 59-2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 7 маендагы 30-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына электрон рәвештә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Законының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы», «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Тәтеш районы прокурорының 2020 елның 27 гыйнварындагы 02-08-02-2020 номерлы протестын караганнан соң, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 7 маендагы 30-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3 бүлекнең 2.3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«2020 елның 1 октябренә кадәр Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан да ким булмаган яки өч елдан да ким булмаган эш стажына карата таләпләр булуны күздә тота.

2020 елның 1 октябреннән соң әлеге нигезләмәнең 2.3 бүлегендәге 2.3.3 пунктының 1 пунктчасында каралган әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән һәм әлеге нигезләмәдә каралган квалификация таләпләренә туры килә торган муниципаль хезмәткәрләргә кагылмый.»;

1.2. 4.1 бүлекнең 4.1.3 пунктының 4 пунктчасындагы 2.7.15 пунктындагы «хезмәт кенәгәсе» сүзтезмәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар сүзтезмәсе белән тулыландырырга»;

1.3. 3.5 бүлекнең 3.5 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез идарәдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция), яллаучы вәкиле рөхсәте белән түләүсез идарә итүдә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер) булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

1.4. 3.4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.4.4 пункты белән тулыландырырга:

«3.4.4. Муниипаль хезмәткәр, күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең

сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

1.5. 3.6 бүлекнең 3.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән тулыландырырга:

«2.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

1.6. 4.2 бүлекнең 4.2.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Җирлектә урнашкан авыл торак пунктларында җирле администрация вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру йөкләнә торган җирле администрация территориаль органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру очрагында, муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен булдыру тәртибе әлеге авыл торак пунктларының һәркайсында гражданнар җыенында күрсәтелгән кандидатураларны аның әгъзалары арасына кертүне күздә тотарга тиеш.»;

1.7. 6.4 бүлекнең 6.4.6 пунктының 2 пунктчасын «хезмәт кенәгәсе» сүзтезмәсеннән соң «һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзтезмәсе белән тулыландырырга;

1.8. Пункт 6.6.2 раздела 6.6 после словосочетания «трудовая книжка установленного образца» дополнить словосочетанием «и (или) сведения о трудовой деятельности»;

1.9. Пункт 6.6.3 раздела 6.6 изложить в следующей редакции:

«6.6.3. Записи в трудовой книжке и (или) сведения о трудовой деятельности, учитываемые при подсчете стажа муниципальной службы, должны быть оформлены в соответствии с трудовым законодательством, действовавшим на день их внесения в трудовую книжку и (или) сведения о трудовой деятельности. В случаях, когда в трудовой книжке и (или) сведениях о трудовой деятельности содержатся неправильные или неточные сведения, которые являются основанием для подтверждения периодов службы (работы), включаемых в стаж муниципальной службы, в трудовую книжку и (или) сведения о трудовой деятельности вносятся изменения в порядке, предусмотренном федеральным законодательством.

В случаях, когда в трудовой книжке и (или) сведениях о трудовой деятельности отсутствуют записи, подтверждающие стаж муниципальной службы, данный стаж подтверждается на основании представленных справок с приложением копий документов о назначении и освобождении от должности, подтверждающих периоды службы (работы) в должностях, которые включаются в этот стаж.»;

1.10. Пункт 6.6.4 раздела 6.6 после словосочетания «в трудовой книжке» дополнить словосочетанием «и (или) сведениях о трудовой деятельности»;

1.11. Пункт 7.2.3 раздела 7.2 изложить в следующей редакции:

«7.2.3. Порядок применения и снятия дисциплинарных взысканий определяется трудовым законодательством, за исключением случаев, предусмотренных Федеральным законом от 02.03.2007 № 25-ФЗ «О муниципальной службе в Российской Федерации».»;

1.12. 7.3 бүлекнең 7.3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе докладының, аны башкаруның факттагы шартлары һәм муниципаль хезмәткәрнең аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән (ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне кулланудан тыш), муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы);»;

1.13. 7.3 бүлекнең 7.3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.9. Әлеге нигезләмәнең 3.6, 3.8 һәм 7.2 бүлекләрендә каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, ялда булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.»;

1.14. 7.3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 7.3.15 пункты белән тулыландырырга:

«7.3.15. Муниципаль хезмәткәргә ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне куллану турында белешмәләр җирле үзидарә органы тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышаныч югалу сәбәпле, муниципаль хезмәт узган затлар реестрына кертелә.».

2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка җиткерергә һәм Тәтеш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU.) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контролдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Монастырск авыл җирлеге башлыгы А.А. Васинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Монастырск авыл җирлеге**
**башлыгы** **А.А. Васин**